## Ноябрь аенда кояш чыгу, кояш бату һәм намаз уку вакытлары

| Көннәр | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Кояш бата Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 6.06 | 7.36 | 13.05 | 15.17 | 17.12 | 18.42 |
| 2 | 6.08 | 7.38 | 13.05 | 15.16 | 17.10 | 18.40 |
| 3 | 6.10 | 7.40 | 13.05 | 15.14 | 17.08 | 18.38 |
| 4 | 6.12 | 7.42 | 13.05 | 15.12 | 17.06 | 18.36 |
| 5 | 6.14 | 7.44 | 13.05 | 15.10 | 17.04 | 18.34 |
| 6 | 6.15 | 7.45 | 13.05 | 15.09 | 17.02 | 18.32 |
| 7 | 6.17 | 7.47 | 13.05 | 15.07 | 17.01 | 18.31 |
| 8 | 6.19 | 7.49 | 13.05 | 15.05 | 16.59 | 18.29 |
| 9 | 6.21 | 7.51 | 13.05 | 15.04 | 16.57 | 18.27 |
| 10 | 6.23 | 7.53 | 13.05 | 15.02 | 16.55 | 18.25 |
| 11 | 6.25 | 7.55 | 13.05 | 15.01 | 16.54 | 18.24 |
| 12 | 6.27 | 7.57 | 13.05 | 14.59 | 16.52 | 18.22 |
| 13 | 6.29 | 7.59 | 13.05 | 14.58 | 16.51 | 18.21 |
| 14 | 6.30 | 8.00 | 13.05 | 14.56 | 16.49 | 18.19 |
| 15 | 6.32 | 8.02 | 13.05 | 14.55 | 16.48 | 18.18 |
| 16 | 6.34 | 8.04 | 13.05 | 14.53 | 16.46 | 18.16 |
| 17 | 6.36 | 8.06 | 13.05 | 14.52 | 16.45 | 18.15 |
| 18 | 6.38 | 8.08 | 13.05 | 14.51 | 16.43 | 18.13 |
| 19 | 6.40 | 8.10 | 13.05 | 14.49 | 16.42 | 18.12 |
| 20 | 6.41 | 8.11 | 13.05 | 14.48 | 16.41 | 18.11 |
| 21 | 6.43 | 8.13 | 13.05 | 14.47 | 16.39 | 18.09 |
| 22 | 6.45 | 8.15 | 13.05 | 14.46 | 16.38 | 18.08 |
| 23 | 6.47 | 8.17 | 13.05 | 14.45 | 16.37 | 18.07 |
| 24 | 6.48 | 8.18 | 13.05 | 14.44 | 16.36 | 18.06 |
| 25 | 6.50 | 8.20 | 13.05 | 14.43 | 16.35 | 18.05 |
| 26 | 6.52 | 8.22 | 13.05 | 14.42 | 16.34 | 18.04 |
| 27 | 6.53 | 8.23 | 13.05 | 14.41 | 16.33 | 18.03 |
| 28 | 6.55 | 8.25 | 13.05 | 14.40 | 16.32 | 18.02 |
| 29 | 6.56 | 8.26 | 13.05 | 14.39 | 16.31 | 18.01 |
| 30 | 6.58 | 8.28 | 13.05 | 14.39 | 16.30 | 18.00 |

*Намаз вакытлары турында мәгълүматларны Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте хезмәткәрләре өзерләде, мөфти Вагыйз хәзрәт ЯРУЛЛИН раслады. Җомга көннәре аерып күрсәтелгән.*

**Учредители: трудовой коллектив редакции газеты «Бердэмлек» и Региональное Духовное управление мусульман Самарской области.**

**Оештыручылар: «Бердәмлек» газетасы редакциясенең хезмәт коллективы һәм Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте.**

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ



# Кыйбла

„БЕРДӘМЛЕК" ГАЗЕТАСЫНЫҢ АЙЛЫК ДИНИ КУШЫМТАСЫ

№ 10
2012 ел
октябрь





*ВӘГАЗЬ*

# Теләнчегә фәкыйрьлек ишеге ачылыр

Пәйгамбәребез (с.г.в.с.): “Өч нәрсәгә ант итәм: *“Бәндәнең малы садака бирүдән кимемәс. Бәндә берәр золымга очраса, аңа сабыр итсә, әлбәттә, Аллаһы аның гыйззәтен өстен кылыр. Бәндә теләнчелек ишеген ачса, әлбәттә, Аллаһы аңа фәкыйрьлек ишеген ачар”. Мин сезгә бер хәдис әйтәм, ятлап куегыз: “Әлбәттә, дөнья дүрт кемсәнекедер. Бер бәндәгә Аллаһы малны да, гыйлемне дә бирә. Ул моның белән Раббысына тәкъвалык кылыр. Аллаһының хакын белер. Бу иң өстен дәрәҗә.*

*Бер бәндәгә Аллаһы гыйлемне ризык кылып бирер, малны бирмәс. Ул изге ниятле булып, әгәр малым булса, фәлән кешенең гамәлен кылыр идем, дияр. Ул ниятенә карата ала. Икесенең дә әҗере бәрабәрдер.*

*Бер бәндәгә Аллаһы малны ризык кылып бирде, әмма гыйлемне бирмәде. Ул гыйлемсез рәвештә малын сарыф итә. Аның белән Раббысына тәкъвалык кылмый. Аллаһының хакын белми. Бу иң начар дәрәҗәдер.*

*Бер бәндәгә Аллаһы малны да, гыйлемне дә бирми. Ул исә, әгәр малым булса, шуның гамәлен кылыр идем дияр. Ул ниятенә карата ала. Икесенең дә гөнаһы бәрабәрдер”,* - диде (Термизи риваяте).

Бу хәдис-шәриф Әбү Кабша әл-Әнмари (р.)дан риваять ителгән. Аның асыл исеме Сәед ибн Әмр булып, сәхабәләрдән булган. Ул Шәмдә яшәгән, хәдисләрне Әбү Бәкр (р.) дан риваять иткән.

Шушы хәдистә Пәйгәмбәребез (с.г.в.с.) кыска җөмләләрдә бик мөһим хакыйкатьләрне безгә ирештергән. Мөһимлеге аның ант итүдән күренә, чөнки әһәмиятсез нәрсәгә ул ант итмәс иде.

«Бәндәнең малы садака белән кимеми». Бәндә үз мөлкәтеннән башка берәүгә садака бирсә, тышкы яктан караганда аның малы садака бирү микъдарына кимүгә охшый. Ләкин асылда исә Аллаһының карашында ул күбәя, һич югында кимеми. Аллаһы Тәгалә садака кылынган малга бәрәкәт бирә, аның урынына башка яктан өстәп бирә. Садакага кылынган мал исә бу дөньядан теге дөньяга күчерелгән була.

Бер төркем адәмнәр Пәйгамбәребезгә (с.г.в.с.): “Суелган хайванның дүрттән бер өлеше генә калды. Калганын садака итеп тараттык”, дигәннәренә: “Дүрттән берсеннән башкасы калган икән”, диде. “Бәндә берәр золымга очраса, аңа сабыр кылса, әлбәттә, Аллаһы аның гыйззәтен өстен кылыр”.

Бу үч алу мөгикинлегенә ия булып та, үзенә золым кылган адәмне гафу кылып җибәрү фазыйләтле эш икәнен күрсәтә. Залимнең золымын кире кагу - һәр мөселманның бурычы. Әмма шәхси мәсьәләләрдә берәүдән золымга очрап, аны кичереп җибәрү дә фазыйләт, чөнки үзара гафу итешү булмаган җәмгыятьтә тәртипсезлек, золым күбәя. Җәмгыять әгъзалары арасында үзара дошманлык көчәя. Нәтиҗәдә мондый җәмгыять түбәнгә тәгәри.

“Бәндә теләнчелек ишеген ачса, әлбәттә, Аллаһы аңа фәкыйрьлек ишеген ачар”.

Бәндә җиңел генә ризык табуга омтылып, ялкауланып, теләнчелекне үзенә мәкбүл күрсә, Аллаһы Тәгалә аны фәкыйрьлек элмәгенә сала.

Ислам кешеләрне маңгай тирен түгеп, хәләл хезмәт аркылы көн күрүгә чакыра. Теләнчелек белән тормыш итү гаепләнә. Гәрчә исламда теләнчелеккә рөхсәт бирелсә дә, чарасыз калганда, тыйнаклык белән кылынуы күздә тотылган. Теләнчелекнең яхшы нәрсә түгеллеге күп хәдисләрдә әйтелгән. Хәтта теләнче теләнеп йөрсә, йөзендә тиресе һәм итләре йолкынган хәлдә кыямәт көнендә терелтелер диелә.

Инде хәдистә дүрт төр кешеләр гөруһларына тукталыйк. Беренче төренә Аллаһы Тәгалә мал-мөлкәт һәм гыйлем-мәгърифәт бирер. Шулар белән ул адәм Раббысына тәкъвалык күрсәтеп яши. Мөлкәтен Аллаһы күрсәтмәләренә таянып, сарыф итә. Гыйлемен дә тәкъвалык юлында файдалана. Малының зәкятен түли, садакалар бүлә, Аллаһы юлында байлыгын сарыф итә, гыйлеменә таянып кешеләрне тугры юлга чакыра. Бу дүрт төркем арасында иң дәрәҗәлеседер. Ягъни исламда һәм байлык, һәм гыйлемлек мактаулы дип санала, һичничек байлык кимсетелми.

Исламда, димәк, байлык начар нәрсә түгел, бәлки, аңа хирыс булу, аны начар юл-